**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге составына керүче Иске Гәрдәле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

05 ноябрь, 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 5 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда яшәү урыны буенча Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәлеавылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстан, Чечня, ЧАЭС авария чернобыль-ликвидаторлар катнашучылары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юл ремонтлау;
- электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **172** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **89** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәлә 89 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда яшәү урыны буенча Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең)

сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, Әфганстан, Чечня, ЧАЭС авария чернобыль-ликвидаторлар катнашучылары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юл ремонтлау;
- электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру.

мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныйрга.

3. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәлеавылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Иске Гәрдәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы — Р.Ф.Адиев